**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «12» июленнән № 35-279

2022 елда мәгарифне үстерү стратегиясе кысаларында 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәгарифне үстерү комплекслы программасын тормышка ашыруның барышы һәм 2023 елга бурычлар турында

«2022 елда мәгарифне үстерү стратегиясе кысаларында 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәгарифне үстерү комплекслы программасын тормышка ашыруның барышы һәм 2023 елга бурычлар турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы урынбасары А. Б.Улитинның мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «2022 елда мәгарифне үстерү стратегиясе кысаларында 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында мәгарифне үстерү комплекслы программасын тормышка ашыруның барышы һәм 2023 елга бурычлар турында» мәгълүматны игътибарга алырга.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә тәкъдим итәргә:

- белем бирү оешмаларын кадрлар белән тәэмин итү эшен дәвам итәргә;
- балаларның психологик халәтен һәм сәламәтлекне саклау эшен тикшерен торуны көчәйтергә;
- белем бирү сыйфатын бәяләүнең муниципаль системасын үстерүне тәэмин итәргә, укучыларның белемнәрен объектив бәяләүне тәэмин итүгә һәм ирешкән уңышлардан нәтиҗәле файдалануга аерым игътибар бирергә;
- дәүләт йомгаклау аттестациясенә сыйфатлы әзерлекне тәэмин итәргә;
- һәр мәктәпнең белем бирү сыйфаты мониторингын алып барырга, ай саен анализларга һәм белем бирүнең сыйфатын күтәрү өчен чаралар күрергә;

- гомуми белем бирүнең сыйфатын күтәрү, Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлек сыйфаты буенча чараларны оештыру өчен шартлар тудыру эшен дәвам итәргә, барлык фәннәр буенча да түбән чикне узучылар санын 100% ка һәм чыгарылыш сыйныф укучылары тарафыннан 100% аттестат алуга ирешергә;

- «Дәрестән соңгы мәктәп» проекты кысаларында өстәмә белем бирү системасын үстерү кысаларында фәнни-техник иҗатны үстерүгә юнәлдерелгән чараларны нәтиҗәле куллануны тәэмин итәргә.

- мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һәм инвалид балаларны өстәмә гомуми белем программалары белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын кабул итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов